ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлегенең Зирекле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 22 ноябреннән № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлегенең Зирекле авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлегенең Зирекле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Зирекле авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү 2021 елда үзара салым кертү.

2. Алынган акчаларны Зирекле авылында түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (Бакча урамы, 1 Май, Г.Тукай урамнары буенча юлларга таш җәю, сатып алу, ташу, грейдлау, катоклау, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- җәйге чорда территориядәне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Урганчинка елгасы аша күпер кичүе корылмасы төзү (төзелеш материаллары сатып алу, торбалар урнаштыру, таш ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Зирекле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// novosheshminsk. tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка танытырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы

Ж.Г. Гайфетдинов